**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» январь 2020 с. Тюлячи № 21

Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә раслау турында

Районда халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү буенча алга таба эш алып баруны тәэмин итү, формаль булмаган хезмәт базарын кыскарту һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне бетерү максатларында, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-891 номерлы "Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча Республика ведомствоара комиссиясе мәсьәләләре" Указының 3 пунктын исәпкә алып, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында Нигезләмәне, 1 номерлы кушымта нигезендә;

- Теләче муниципаль районында Яшәү дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составын, 2 номерлы кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының "Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы Нигезләмәне яңа редакциясендә раслау хакында" 2011 елның 14 февралендәге 63нче карарының 1нче пункты үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә .

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___»________ 2020 ел
_____ номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара район комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Теләче муниципаль районында (алга таба - Комиссия) тормыш дәрәҗәсен күтәрү буенча ведомствоара район комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм җирле үзидарә органнарының халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, формаль булмаган хезмәт базарын кыскарту һәм икътисадта тискәре тенденцияләрне җиңү буенча үзара килешеп эшләүләрен тәэмин итү өчен оешкан коллегиаль ведомствоара орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп, функцияләре һәм бурычлары булып торалар:

- социаль-икътисадый өлкәдә тенденцияләргә, шулай ук әлеге өлкәдә район муниципаль хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә торган карарларның халыкның тормыш сыйфатына йогынтысы мониторингын үткәрү;

- хезмәт базарын тотрыклыландыру, керемнәрне легальләштерү, күләгәле икътисад һәм формаль булмаган хезмәт базары йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән тискәре тенденцияләрне җиңү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

- эш бирүчеләрнең минималь куллану бюджеты хакыннан һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен түләүдән ким булмаган күләмдә хезмәт хакын вакытында түләвен тәэмин итүгә, шулай ук халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның реаль керемнәрен арттыру буенча чаралар эшләүгә юнәлтелгән чаралар эшләү;

- формаль булмаган икътисад һәм хезмәт базары тенденцияләрен һәм масштабларын ачыклау максатында социологик тикшеренүләр үткәрү турында тәкъдимнәр әзерләү;

- район территориясендә урнашкан барлык оештыру-хокукый формадагы хуҗалык объектларының чыгымнар структурасын үзгәртүне анализлау, әлеге базада өстәмә кыйммәтне арттыру, хезмәт хакын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- хуҗалык итүче субъектларның алдан уйлап төзелүен яисә түләүгә сәләтлелеген арттыруга юнәлдерелгән эш-гамәлләрне тормышка ашыру өчен милекчеләр тарафыннан үз вакытында идарә итү карарларын кабул итү өчен

тәкъдимнамәләр эшләү максатында кризислы хәлдәге хуҗалык субъектлары эшчәнлегенә мониторинг ясау;

- җирле үзидарә органнары инициативасы буенча район территориясендә урнашкан аерым хуҗалык субъектларының бөлгенлеккә төшүен кисәтү чаралары турындагы тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук бөлгенлек (банкротлык) процедураларын башлап җибәрүгә вәкаләтле органнарны карауга әзерләү һәм кертү, әлеге хуҗалык субъектларына карата тәкъдимнәр кертү;

- районда социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын, адреслылыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

4. Комиссия хокуклы:

- үз утырышларына башка вазыйфаи затлар, җирле үзидарә башкарма органнары, территориаль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, шулай ук эш төркемнәре (советлар, комиссияләр), хуҗалык итүче субъектларның җитәкчеләрен чакырырга;

- Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук хуҗалык итүче субъектлардан тиешле документларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

- Комиссия ачыклаган бозуларны бетерү максатыннан, законнар нигезендә карарлар кабул итү өчен башкарма хакимият органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрергә;

- кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә, Комиссия компетенциясенә керә торган карарларны һәм башка материалларны әзерләүдә катнашу өчен, хуҗалык субъектлары башкарма хакимиятенең федераль һәм территориаль органнары белгечләрен җәлеп итәргә;

- комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эш төркемнәре булдырырга.

5. Комиссия составына Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты, Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы министрлыкларының һәм ведомстволарының Теләче муниципаль районындагы территориаль органнары вәкилләре керә.

6. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия рәисе тарафыннан расланган план буенча башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен,кимендә айга бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Утырыш беркетмәсенә комиссия

рәисе кул куя.

8. Комиссия рәисе:

- Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота;

- Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;

- Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче карарлар кабул итә.

9. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

- Комиссия кабул иткән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли.

10. Район Башлыгы, район Башкарма комитеты Җитәкчесенең карарларын таләп итә торган Комиссия тәкъдимнәре , район Башлыгы, район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан йөкләмәләр һәм карарлар проектлары рәвешендә рәсмиләштерелә. Әлеге проектлар комиссия рәисе тарафыннан визирлана һәм, димәк, район Башлыгына, Башкарма комитет Җитәкчесенә карау һәм карар кабул итү өчен җибәрелә.

11. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү район Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

12. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән Комиссия үз эшчәнлеген туктата.

13. Комиссия карарларына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___»________ 2020 ел
_____ номерлы карарына
2 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара район комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Хаҗипов Н.Н. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Миңнегулов И.Ә. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Галимҗанов Р.А. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге баш белгече, комиссия секретаре; |
| Галимҗанов А.М. | - | "Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Низаметдинов Р.Х. | - | Теләче муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Яхин Р.Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Шиһабетдинов И.С. | - | баш Дәүләт салым инспекторы - РФ Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 10 номерлы районара бүлегенең Теләче участогы эше өчен җаваплы (килешү буенча); |
| Зарипов И.С. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Шәфигуллина Г.Н. | - | Дәүләт статистикасы пунктының Алабуга ДСБ бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча); |
| Мөһтәсимов М.М. | - | ТР Теләче районында РФ пенсия фонды бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Мирайханова Ч.И. | - | Теләче муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе; |
| Зәйнетдинова З.Р. | - | Теләче районы буенча вәкаләтле вәкил - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча дәүләт идарәсенең 8 номерлы филиалы баш белгече (килешү буенча); |
| Ибраһимов Р.Р. | - | Теләче районы прокуроры ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Хәбибуллина Н.Р. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы һөнәр берлекләре оешмаларының Координация советы рәисе. |